Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авыл Советы

# КАРАРЫ

02 август 2021 ел №18

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 116 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2021 елның 29 мартындагы 02-08-02/366 номерлы күрсәтмәсен карап,

Ямаши авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында» 2014 елның «19» ноябрендәге 116 номерлы карарына (2015 елның 05 маендагы 142 номерлы, 2015 елның 29 октябрендәге 5 номерлы, 2018 елның 20 августындагы 89 номерлы, 2019 елның 06 маендагы 109 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 3 пунктның уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым ташламасы бирелә торган сайланган объектлар турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан салым органына үзенең сайлау буенча салым чорыннан башлап шушы объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча тапшырыла. Салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт яисә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Ямаши
авыл җирлеге башлыгы А.А. Андревкина